| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ<br>МАЛОБУИНКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР БУАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 06 февраль 2023 ел | № 63-1 |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2013 елның 05 февралендәге 2-33 номерлы карары белән расланган Татар Буасы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә (27.06.2016 № 14-2, 20.09.2016 № 18-1, 23.09.2017 № 37-1, 12.02.2019 № 61-1, 22.06.2021 № 22-1, 01.03.2022 № 38-2, 04.05.2022 № 44-1, 08.07.2022 № 48-1, 24.10.2022 № 57-1, 20.12.2022 № 60-1 карарлары редакциясендә) (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 22 статья :

2 өлешенең 4 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«ярдәмче куллану корылмалары һәм өзелмәләрне төзү, аларны кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.;»;

1.2. 42 статья:

2.3 өлешенең 11 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, аларны эксплуатацияләү, сервитут шартларында реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү максатларында автомобиль юлларының бүленгән полосалары чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдалану, инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү, яңадан урнаштыру, гавами сервитут шартларында алардан файдалану максатларында җир кишәрлекләреннән файдалану.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Йосыпов